УДК 811(=512.145)

***И.Б. Бәширова***

# «ӘДӘБИ ТЕЛ ТАРИХЫ – АНЫҢ СТИЛЬЛӘРЕ ТАРИХЫ»
## *(Латыйф Җәләйнең тууына 130 ел тулу уңаеннан)*

Статья посвящена 130-летию со дня рождения доктора филологических наук, профессора Латифа Заляя. Автор исследования описывает научные достижения ученого, подчеркивая их актуальность и в настоящее время. Научная деятельность исследователя многогранна: он определяет понятие история татарского литературного языка, анализирует историю его стилей, поясняет сущность понятий стиль и стилистика. Л. Заляй научно обосновывает теорию стилистики – это отрасль науки, изучающая неодинаковые для разных условий языкового общения принципы выбора и способы организации языковых единиц. По мнению ученого, сформировавшийся литературный язык делится на пять стилей. Он, перечисляя стили татарского литературного языка середины XX века, выделяет присущие им термины, объясняет их историю. Исследователь отмечает, что практическая стилистика и практическая грамматика имеют общую основу, но при этом делает акцент на том, что их функциональные задачи различаются. Также Л. Заляй ведет научную деятельность по таким направлениям, как история татарского языка, татарская грамматика, татарская диалектология. Он защищает кандидатскую и докторскую диссертации, долгие годы читает лекции студентам, пишет рецензии на литературные произведения, написанные в разных жанрах. В этой статье, опираясь на теоретические обобщения Л. Заляя, определяются стили, сформировавшиеся в истории татарского литературного языка. Здесь впервые высказывается мысль, что до художественного стиля в традициях богословского учения существовал стиль, который автором статьи определяется, как художественный божественный / духовный / человеческий стиль.

**Ключевые слова:** Латиф Залялетдинович Заляй, история татарского литературного языка, стиль, стилистика, функциональный язык, функциональные стили.

The article is dedicated to the 130th anniversary of the birth of Doctor of Philology, Professor Latif Zalyai. The author of the study describes the scientific achievements of the scientist, emphasizing their relevance today. The researcher's scientific activity is multifaceted: he defines the concept of the history of the Tatar literary language, analyzes the history of its styles, explains the essence of the concepts of style and stylistics. L. Zalyai scientifically substantiates the theory of stylistics – this is a branch of science that studies the principles of choice and methods of organizing language units that are different for different conditions of language communication. According to the scientist, the formed literary language is divided into five styles. Listing the styles of the Tatar literary language of the mid-twentieth century, he highlights the terms inherent in them, explains their history. The researcher notes that practical stylistics and practical grammar have a common basis, but at the same time emphasizes that their functional tasks are different. L. Zalyai also conducts research in such areas as the history of the Tatar language, Tatar grammar, and Tatar dialectology. He defends his candidate and doctoral dissertations, has been lecturing to students for many years and writing reviews of literary works written in various

genres. In this article, based on L. Zalyai's theoretical generalizations, the styles that have formed in the history of the Tatar literary language are defined. Here, for the first time, the idea is expressed that before the artistic style in the traditions of theological teaching, there was a style that the author of the article defines as an artistic divine / spiritual / human style.

**Keywords:** Latif Zalyaletdinovich Zalyai, history of the Tatar literary language, style, stylistics, functional language, functional styles.

Бу мәкалә татар тел белемендә беренче фән докторы, төрки дөньяда танылган галим, киңкырлы уку-укыту эше белән шөгыльләнгән профессор-педагог Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдиновның (Л. Җәләй) тууына 130 ел тулу мөнәсәбәте белән языла. Л. Җәләй 1894 елның 17 ноябрендә Ульяновск өлкәсе Кече Кандал районы Иске Кызыл Су (русча: Тат. Урайкино) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башта авыл мәктәбендә укый, 1906 елдан Мәләкәс мәдрәсәсендә белем ала, 1912 елдан укытучылык эшенә керешә.

1915 елда Л. Җәләй солдатка алына, сугышта контузияләнә, госпитальдән чыккач, яңадан фронтка китә. Февраль революциясен – Румыниядә, Октябрь революциясен туган авылында каршылый. Укыту белән шөгыльләнә, төрле өязләрдә мәгариф бүлегендә эшли. 1929–1931 елларда башта Кузнецк шәһәрендә, аннан Мәләкәстәге партия мәктәбендә татар теле укыта, Самара педагогия институты каршындагы аспирантурага керә.

1933 елда Л. Җәләй Казанга килеп, педагогия институты каршындагы аспирантурада укуын дәвам итә. 1935 елда аны тәмамлый һәм шунда ук эшкә дә калдырыла: әдәби тел тарихы, тарихи грамматика һәм диалектология курсларын алып бара. Шуның белән бергә, яшь әдипләрнең беренче хикәяләренә рецензияләр язуын дәвам иткән хәлдә [5], стилистика дип башлана торган берничә мәкалә яза: «Стилистика һәм әсәрнең композициясе. Тәрҗемәчеләр белән укыр өчен бер курс (1934, 36 б.); «Стилистика һәм гомуми тел белеме буенча язмалар» (1935, 38 б.). Мәкаләләр Яңалифтә ныклы система-план белән язылган. Башта «Стиль – тар һәм гади мәгънәдә алганда, «форма-рәвеш», ягъни эш яки предмет-әйбер формасы. Мәсәлән, иптәш Сталинның «Эштә Ленин стиле» дигән тәгъбире кулланыла. Бу бина яңа стильдә салынган. Бу кешенең сөйләү стилендә борынгылык чагыла» һ. б. мисаллар ярдәмендә стиль төшенчәсенең мәгънәсе аңлатыла. Аннан соң «Стиль сүзе борынгы римлыларда кискеч, кыргыч, кинжал, каләм мәгънәсендә кулланыла. Стиль – балавызлы тактага язу коралы. Соңыннан язу формасы, язу алымы төшенчәсенә күчә. Гомумән, фикер тәгъбире формасы. Пушкин һәм Лермонтов стильне кинжал мәгънәсендә кулланалар», дип, әлеге сүзмәгънәнең тарихи үзгәреше күзаллана. Автор үз чоры идеологиясенә туры китереп, бу сүзнең социаль мәгънәсе һәм аңа карата фикерләр бар дип, «Буржуазия стильне индивидуальләштерә, димәк, стильнең сыйнфыйлыгын, аның экономик сәбәпләр, сыйныфлар көрәше белән нык

бәйләнештә һәм шушы нигездә үсүен карамый. ...Марксизм каршында, стиль сыйнфый. Иптәш Сталинның «Эштә Ленин стиле» дигән мәкаләсе бар. Буржуазиядә – коры практивизм. Революциядә – революцион теория һәм революцион практика» дип, буржуазия һәм марксизм карашының терминда ничек чагылышы аңлатыла: «Димәк, а) стиль – ул бер әдәбият, телгә караган нәрсә генә түгел, ә) стиль – ул сыйныфның яшәү, көрәш, үз интересларын яклауда кулланылган алым үзенчәлекләреннән тора», дип нәтиҗә ясала. Аннан соң, стилистика дигән фән тармагының максат-бурычы билгеләнә: «Беренчедән, стильнең әдәбиятта, фәнни, политик, художество һәм йомышлы әдәбият күзлегеннән карап алынган төшенчә булуын күрәбез. Стилистика – ул әдәбиятта кулланыла, стиль турында белем дигән сүз. Димәк, без хәзер стильдә тел фактларының сөйләм практикасына карата кулланылыш функциясен күрәбез» [6]. Шулай итеп, татар тел белемендә беренче мәртәбә стилистика дип атала торган фән тармагының предметы / табигате һәм вазифасы билгеләнә: стилистика – ул, тел берәмлекләренең сөйләм барлыкка китерү үзенчәлеген тикшерә торган фән тармагы. Стилистиканың әлеге максатын Л. Җәләй үзенең «Практик стилистика алдында торган төп бурычлар» дигән мәкаләсендә тәгаенли: аның практик грамматика белән охшаш һәм аермалы якларын күрсәтә. «...Практик стилистиканы практик грамматика белән һичбер вакытта да алмаштырырга ярамый. Уртаклык һәр икесенең дә тел-сөйләм чараларының бер үк объектлары... өстендә эшләүләреннән гыйбарәт. Аерма – объектларны үзләренчә ачыклауларында. Мәсәлән, грамматикада тел-сөйләм практикасындагы фактлар (авазлар, сүзләр, җөмләләр) билгеле нормаларга салына, ...эчтәлек һәм форма берлеге ягыннан билгеләнә; практик стилистикада шул ук объектларның ...стиль-сайлау культурасы ягыннан ятымлырак, төшенчә, уй-фикерләр бирүдә баерак булулары мәсьәләсе, ягъни художество, эмоция ягыннан эшләнеш формалары күзәтелә» [7]. Димәк, әлеге мәсьәлә истә тотылмыйча, морфологик кушымчаның стилистик кулланылышы дип өйрәнелгән очракта, практик грамматика турында сөйләгән булабыз. Аңлашылганча, стилистика дип өйрәнгәндә, тел берәмлеге тоташ сөйләм (җөмлә) эчендә, стиль-сайлау культурасы ягыннан карап анализлана. Шулай итеп, XX гасырның 30 нчы еллары уртасында, татар тел белемендә беренче мәртәбә стилистика дип аталган фән тармагының үзенә хас табигате һәм вазифасы билгеләнә, теориясе һәм практик нигезе ассызыклана. Алга таба әлеге мәсьәләләр «Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең аерымланган кисәкләре» [8], «Әдәби телне өйрәник....!» [9], «Татар теле әдәби теле туу мәсьәләсенә карата» мәкаләләрендә [10] төрле яклап яктыртыла.

Л. Җәләйнең бу еллардагы һәм алдагы чорлардагы эшчәнлеген күзәтү барышында, стилистика тармагы өйрәнелә башлау белән бергә, татар теле тарихы, диалектология, тарихи грамматика һәм әдәби тел тарихы өлкәләренә караган фәнни юнәлешнең дәвам иттерелүе күренә. «Татар теле тарихына карата кайбер материаллар» дигән

хезмәтен галим 1938 елда кандидатлык диссертациясе итеп яклый. Казан педагогия институтында укытучылык эшен дәвам иткән хәлдә, 1939 елдан Татарстан Мәгариф халык комиссариаты карамагындагы Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтында (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли башлый. 1956 елдан 1962 елга кадәр Тел бүлеге җитәкчесе вазифасын башкара. Бер үк вакытта Казан дәүләт университетында Татар теле һәм әдәбияты бүлеген оештыруда да актив катнаша, анда диалектология һәм тел тарихы курсларын алып бара. 1938 елда басылган «Татар телендә диалектлар» дигән мәкаләсендә нигезләнгән фикерләре гомумиләштерелеп, системага салына, 1947 елда «Татар диалектологиясе» дигән дәреслеге дөнья күрә. 1955 елда «Татар теленең урта диалекты турында монография» дигән хезмәте докторлык диссертациясе булып яклана. Академик Н.К. Дмитриев тарафыннан ул: «Безнең алда татар фәнендә әле моңарчы күрелмәгән грандиоз хезмәт, һәм бу Сөембикә манарасыдай һәйкәлгә автор үзенең бөтен яшьлеген, кыю һәм иҗади эзләнүләренең бөтен ялкынын салган» [4], дип бәяләнә.

Бу елларда Л. Җәләйнең әдәби тел турында язылган мәкаләләренең бер өлеше басылган [8; 9; 10], кайберләре басылмый калган: «Татар әдәби теле тарихы тармагыннан тикшеренүләр. «Әдәби тел» төшенчәсе» (1954–1955, 19 б.); «Болгар-татар чоры әдәби телендәге төп стильләр (1958, 84 б.) һ. б.

Казан дәүләт университетында «Татар диалектологиясе», «Татар теленең тарихи грамматикасы», «Татар әдәби теле тарихы» һәм «Татар әдәби теленең стильләре» дигән махсус курслар буенча лекцияләр укыганда, мәкаләләрендә язма стиль таләп иткәнчә бирелгән фикерләрен сөйләм телендә тәгаенләп җиткергәнлеге аңлашыла. Мәсәлән, «Әдәби телне өйрәник!» мәкаләсендәге «Әдәби тел, гомумхалык теленә нигезләнгән килеш, шушы халыкның җәмәгатьчелек фикере, психологиясе, тормышны танып-белүе, культурасы формалашу процессында туган, камилләшкән һәм фәнни, әдәби эшкәртелгән стильләр суммасыннан тора», дигән фикере лекциясендә түбәндәгечә әйтелә: «Әдәби тел нигезендә ничә багана торырга тиеш соң? Беренчедән, әлеге тарихны туа башлаган чорыннан ук өйрәнергә кирәк, гадәттә XVI–XVIII йөзләрдән башлап кына тикшерелә; икенчедән, халыкның экономикасы төзелү белән бәйләп өйрәнелергә тиеш, телне тормыштан аерырга ярамый; өченчедән, әдәби телнең күрсәткече – язу, шуңа күрә ул язу тарихы белән бергә алып барылырга тиеш; дүртенчедән, халыкларның гомуми телләре формалашуда диалектларның үсеше зур урын алып тора, шул үсешнең тарихы исәпкә алынырга тиеш; бишенчедән, әдәби телнең гомумхалык теленнән аермасы – стиль булуда, ул – стильләр тарихы». Сүз уңаеннан, «функциональ тел» төшенчәсенә дә мөнәсәбәт белдерелә: «...кайбер халыклар, сөйләштә үз телләре булса да, әдәби тел рәвешендә икенче халык телен йөрткәннәр. Европа халыкларында шундый тел борынгы латин теле

була. Татар теле тарихында гарәп теле тулаем әдәби тел функциясен үтәми, мәчет әдәби теле булып кала: намаз гарәпчә укыла. Аерым галимнәр китапларын гарәп телендә язганнар. Дини китаплар да гарәпчә генә түгел, күбрәк татарча да язылган, динне халыкка тизрәк җиткерү өчен...» (шәхси архивтан. – *И.Б.).* Мин дә Л. Җәләйнең лекцияләрен тыңлаган бәхетле кешеләрнең берсе булдым.

«Татар әдәби теленең стильләре» дигән лекциясендә, профессор Л. Җәләй: «Формалашып җиткән әдәби тел биш стильгә бүленә, аларның һәрберсенең тарихы бар», – дип, түбәндәге сөйләм стильләрен күрсәтә: сәнгатьчә әдәбият стиле, фәнни һәм фәнни-популяр әдәбият стиле (гыйльми әсәрләр теле стиле), публицистика (иҗтимагый-политик темаларга караган) стиле, йомышлы (эш кәгазьләре) стиле, хатлар язу стиле. Алга таба һәр стильнең үзенчәлеге, билгеле бер дәрәҗәдә тарихы күзаллана. Мәсәлән, фәнни әдәбият стилендә кулланылган термин төшенчәсе турында мәгълүмат бирелә: «Термин – борынгы латин сүзе – чик, граница, предел, чик саклый торган Алла. Ул бер таш була. Хәзер сүзгә күчкән. Терминнар – синонимнары булмаган сүзләр. Борынгы әдәбиятта истыйлах дип йөртелгән. К. Насыйри шулай ди. Һәрбер әдәби телдәге терминнар ике төркемгә бүленә: а) үзьяшәешле (самобытные термины) – һәр телнең үз материалы, татарча: адым, колач, өчаяк һ. б.; б) алынмалар: бездәге тәм, гарәп теленең тәгам – аш, ашамлык сүзеннән; сәләт – сәляхият сүзеннән һ. б. Иң борынгы алынмалар Кытайдан булырга кирәк, төрки халыклар алар белән элемтәдә торалар: креп-де-шин – кытай материалы; апил-син – кытай алмасы, кувшин – күкшин, куыкшин – кытай куыгы һ. б. Кытайлар һәрбер алынма сүзне үз телләренә яраштырып, үз кагыйдәләренә туры китереп үзгәртә торган булганнар. Икенче төркем – фин-угорлардан (кызганыч, мисаллар язылмаган). Өченче катлам фарсыдан килә, боларның күбесе сәүдәгә карый һәм кеше исемнәре: Сөмбел, Маһинур, Маһруй. Көн исемнәре дә фарсыдан: шинбә – көн; якьшәнбә – беренче көн; дүшәмбә – икенче көн; сиһшәнбә – сишәмбе – атнаның өченче көне, буш көн; чәһаршәнбә – чәршәмбе – дүртенче көн; пәнҗәшәнбә – бишенче көн; җомга (монысы гарәп теле сүзе) – атнаның алтынчы көне исеме. Дүртенче катлам – гарәп теленнән кергән алынмалар: дин, ишан, мәсҗид – мәчет, гөнаһ, мөэмин, мөселман, сәяхәт, каләм һ. б. Бишенче катлам – рус теленнән алынган, күбесе хуҗалыкка карый: XIII йөздән – пич, ызба; XVIII йөздән – печать һ. б.

Эш кәгазьләре стиле болай дип аңлатыла башлый: «Бу стильгә конкретлык хас, аны бизәкләү кирәкми. Беркетмә язганда шигырь кыстыру кирәкми. Бу стиль шаблонга корылган, доклад, чыгыш әкият дип аталмый. Татар тарихында ташъязмалар булган, ярлыклар булган. Алар халык телендә язылган, уйгур әлифбасында язылганнары да бар (шәхси архивтан. – *И.Б.*) Гомумтөркигә караган V–VIII гасыр Орхон-Енисей, Күлтәгин, Төньюкук ташъязмаларыннан алынган күпсанлы мисалларны автор «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» хезмәтендә һәр сүз төркемен аңлатканда файдалана [11].

Беренче күрсәтелгән сәнгатьчә әдәбият стиленә тарихи планда соңыннан гына игътибар ителә. 1) Язма тел һәм сөйләмә тел мөнәсәбәте хакында әйтелгән төрле фикерләр китерелә, аларның аермасы искәртелә: сөйләм ат кебек чаба, ә язма тел җәяүләп кенә бара, кем дә кем сөйләшкәнчә язса, хәтта үтә оста сүзле кеше булса да, ул – надан кеше. А.С. Пушкин болай дигән: «Язу теле сөйләү теленә нигез була алмый». Язу теле сөйләү теленнән алынган тәгъбирләр белән җанландырыла. Сөйләшү теле белән генә язу, язуны (телне) белмәү дигән сүз. Язу теле сөйләшү теленә генә тәңгәл була алмый, – дип, Л. Җәләй кайбер әдипләрнең әсәрләреннән алынган мисалларны анализлый: «Бездә сөю һәм ярату бар. Бәрәңге яратам, ләкин сөям түгел. Болай дигән кеше татар булмый. Руста барысы да любить. Ярату – кешенең тышкы дөнья белән мөнәсәбәте, интим нәрсә түгел. Сөю-психологик эчке дөнья: ата-ана сөюе. Бездә матурлык төшенчәсенә йөри торган 20–25 сүз бар, ә монда бер абзацта – 4 тапкыр матур, 3 мәртәбә – пычрак, өчесе дә урынсыз...», – дип, яшь язучы Р. Ишморатованың хикәяләрендәге сүз кулланылышын күздән кичерә (Шәхси архивтан. – *И.Б.*).

Г. Бәширов, А. Шамов, Н. Исәнбәт, Ә. Исхак, К. Нәҗми, Ш. Камал әсәрләренең теленә карата мактау сүзләре әйтелү белән бергә, мәкалә итеп бастырганда, җитешсезлекләр дә күрсәтелә. Г. Бәшировның «Сиваш» повестена җентекле анализ ясап, болай дип яза: «Поэтик синтаксис таләпләре ягыннан килгәндә исә, бу өзектә бер кимчелек бар. Өченче җөмлә белән дүртенче җөмләне автор аерым-аерым үзбаш итеп куйган, минемчә, боларны тезмә кушма җөмләне каршы кую формасында бирү тарихны тулырак чагылдырыр иде, ... “бу чакта” сүзен ташларга, ягъни экономия ясарга да мөмкин булыр иде», – дип, башка җөмләләрне анализлагач, «Разин иптәшнең абайсызланып, һәм шуның аркасында, поэтик синтаксис таләпләрен бозып, монотоник бер алым биреп, кушма җөмләнең затын китәрүенә мисал булып тора. ...Мин уйлыйм... “-тан-тән, -ганда-гәндәләр” белән дыңдырдап торган монотоник аһәңсез, уйгынлык һәм тойгынлыкка кимчелек китерә торган сүзләр тезмәсен ташлаган һәм икенче вариантта биргән булыр иде» [13]. Шул рәвешле, «Үч» җыентыгындагы хикәяләренең һәр җөмләсе диярлек анализлана [14]. Г. Бәшировның, «Намус» романы турында авторга язган хатында болай диелә: «Менә инде моннан соң сәнгатьчә пешүе килмәгән әсәр язучыларның базары бетте. Моннан соң начар әсәр язарга ярамый, чөнки “Намус”ны укып, халыкның зәвыгы үсәчәк. ...Синең “Намус”ың татарны роман укырга өйрәтте. Бу – һичкем тана алмаслык тарихи факт» [15].

Шулай итеп, Сәнгатьчә әдәбият стиленең тарихы дигәндә, әдәби телнең сөйләмә һәм язма формаларда була алуы хакында кыскача мәгълүмат бирелә. Үзенең чордашы булган Г. Бәширов, А. Шамов, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми, һ. б. әдипләрнең әсәрләре өйрәнелү уңаеннан, авторның аерым сүзләрне ничек куллануын күзәтү белән бергә, җөмлә төзелеше үзенчәлегенә игътибар итү зарурлыгына да басым ясала.

Әдәбиятның сәнгатьчәлеген, ягъни әсәрнең нәфислеген, әдәбилеген тикшергәндә, аңа укучының зәвыгын үстерү ягыннан карап, тулаем анализ ясарга кирәклеккә игътибар ителә.

Шуның белән бергә, Л. Җәләй үз вакытында «Тукай телендә фигыльләр» дигән мәкаләсендә: «Тукай телен өйрәнү – татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү, дигән сүз. Кешелек дөньясы барлыкка китергән культура байлыгын тәнкыйть үтәзеннән сөзеп алмый торып, яңаны төзеп булмый. ...Тукай телен өйрәнүне теоретик нигезләү хәзерге телдәге бик күп мәсьәләләрне һәм фәнни, һәм практик яктыртуга мөмкинлек бирәчәк», дип, сүз белән сурәт ясау мөмкинлегенә тарихи нигездән карарга кирәклеген искәртә [12: 84–103]. Бу контексттан, Тукай телен анализлагандагы кебек, башка әдип, шагыйрьләрнең иҗатына да, «татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дип» якын килү сорала.

Татар язма теле баскычларының башлангычы гомумтюркологик хезмәттә билгеләнә. «Языки мира. Тюркские языки» энциклопедик басмасында, төрки телләр гаиләсендәге 15 борынгы һәм 39 хәзерге халык теленең язмачылык тарихы V–VI, XIII–IX, X–XII йөзләрдә башланып, XII–XIII йөздән үз дәүләтендә язылган истәлекнең язылу датасы билгеле булган иске язулы телләр (старописьменные языки) дигәндә, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә санала [33]. Язма истәлек дигәндә, Идел Буе Болгар дәүләтендә Кол Гали тарафыннан 1233 елда сәнгатьчә югарылыкта иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы истә тотыла. Димәк, Кол Галинең, үлемсез әсәре белән, халкыбызны иске язулы телләр рәтендә раслаткан мәшһүр шәхес булуын да онытырга ярамый.

Татар әдәби теле тарихының XIII йөздән башлап өйрәнелүе уңаеннан шуны әйтергә кирәк: иске язулы телләр әдәби язма тел нормасына нигезләнә, алга таба норма традиция буларак дәвам иттерелә, аерым дәүләттә (төбәктә) яшәүчеләрнең сөйләм телләре белән баетылу язма норманың төрле вариантлар белән кулланылуына китерә [25: 10–17]. Бу яктан караганда, остазыбыз Л. Җәләйнең сәнгатьчә әдәбият стиле дип аңлатыла торган күренешне XX гасырның 30–40 нчы елларында иҗат ителгән аерым проза әсәрләрен санап-анализлап кына күзалларга тырышуы тарихи объектив дөреслеккә туры килеп бетми. Мәдрәсәдә дини гыйлем алган Л. Җәләй сәнгатьчә әдәбият стилен «татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычы» дип караганда, аның башка стильләрдән аерыла торган үз тарихы булуын, бу тарихның бисмилләһир-рахманир-рәхим дип, Аллаһы Тәгаләне гүзәл атамалары белән мактап, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне зурлап, ягъни Илаһият тәгълиматы традициясендә башлануын яхшы белсә дә, бу хакта сүз кузгата алмый. Чөнки татар халкының, аның теле, әдәбияты, мәдәниятенең тарихы бар дип расларга тырышкан Бертуган Шәрәфләр, Г. Рәхим, Г. Газиз, С. Вахиди, Җ. Вәлиди, С. Җәләл, Г. Ибраһимов һ. б. ның фаҗигалы язмышка дучар ителүенә үзе дә шаһит була.

XX гасырның соңгы елларында гына, иҗтимагый-сәяси хәлләргә объектив дөреслек күзлегеннән мөнәсәбәт белдерү мөмкинлеге ачылгач, төрки-татар әдәбиятында барлык жанрларның да, гасырлар буена Илаһият тәгълиматына нигезләнгән иҗади традициядә, дөньяви чынбарлыкның тасвирлануы белән яңартылып, сәнгатьчә эшчәнлек бару турында фикер кузгатыла, хезмәтләр языла башлый. Казан дәүләт университетында гарәп теле укыткан Җ.Г. Зәйнуллинның «XVIII – XX йөз башында татар рухани әдәбияты: Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ. б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре» дигән хезмәте дөнья күрә [16]. «Рухани әдәбият татар мәдәниятенең зур һәм гаять әһәмиятле бер катламын тәшкил итә. Берничә гасыр дәвамында тудырылган дини эчтәлекле тәрҗемә әсәрләр – «Коръән тәфсирләре, хәдисләр, шәрехләүләр), дин фәлсәфәсе өлкәсендә эшләгән күренекле галимнәребезнең кыйммәтле мирасы, дин гамәлләре, дини тәрбия һәм үгет-нәсыйхәт эчтәлекле күпсанлы китаплар һ. б. бүгенге көнгә кадәр өйрәнелмәгән хәлдә кала килә», – дип яза галим. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен чыгарылган «Татар стилистикасының теоретик нигезләре» дигән программа-кулланмада татар әдәби теленең Л. Җәләй санаган гамәлдәге биш стиленә алтынчысы – дини-дидактик стиль өстәлә; аның башка стильләрдән үзенә генә хас табигате һәм вазифасы белән аерымлануы билгеләнә [2: 21–25].

Иң мөһиме, XXI гасырның беренче унъеллыгында сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы» академик басмасы аның төзүчесе һәм җаваплы мөхәррире Р.Ф. Рахманиның: «...Фәлсәфи яктан материалистик, атеистик, большевистик идеологиягә хезмәт иткән әсәрләрне генә алга чыгарып, психологик тирәнлекләргә төшмичә, әдәби әсәрләрне барлауда, нигездә, штамп фикергә иллюстрация эзләү белән чикләнеп, без аң һәм җан яшәешен, эстетик үсешебезне таш диварга китереп терәдек, чөнки ике мең еллык әдәби ядкярләребез, – асылда, тулаем ачык иманлы, дини карашлар белән камил үрелгән югары сәнгатьле рухи хәзинә», – дигән фикерләре белән башланып китә [29]. Татар әдәби теле тарихын өйрәнү барышыннан күренгәнчә, Илаһият тәгълиматына нигезләнгән иҗади традициядә автор аңында эстетик кабул ителгән дөньяви чынбарлыкның, максатка туры китерелгән нәфис сүз-сурәтләр белән тасвирлы яңартылган сәнгатьчә эшчәнлек буларак, гасырлар буена дәвам итүе аңлашыла. Әлеге мәсьәләләрнең, танылган телче һәм әдәбиятчы галимнәребез тарафыннан җентекләп өйрәнелеп, укучыларга тәкъдим ителүе мәгълүм. Аларның фикерләрен зиһендә тоткан хәлдә, остазыбыз Л. Җәләй белдергәнчә, «татар әдәби теле тарихы – аның стильләре тарихы ул» дип тикшерү барганда, бу юнәлештәге катлаулы проблемаларны хосусый фән кысасында, ныклы системада күзаллау өчен, язма текстларны, аерым стильләргә бүлеп, махсус аңлату көтелә.

Әйтеп үтелгәнчә, тарихи яссылыкта караганда, сәнгатьчә әдәбият стиленә хас үзенчәлек XX йөзнең 40–60 нчы елларында язылган әдә-

би әсәрләрне өйрәнү белән генә билгеләнә алмый. XII–XIII йөзләрдән татар әдәби теленең сәнгатьчә әдәбият стилендәге колачын, табигатен һәм вазифасын күзаллау өчен, татар әдәбияты тарихында «тулаем ачык иманлы, дини карашлар белән камил үрелгән югары сәнгатьле рухи хәзинә» булган язма истәлекләребезнең үзенчә формалашкан жанр төрләрендә илаһият тәгълиматы нигезендә сәнгатьчә сурәтләнүен тулаем зиһенгә алып тикшерергә, заманасына карап, яңарышны билгеләргә кирәк.

Сүз уңаеннан, сәнгатьчә әдәбият стиле дигәндә, хосусый терминның тәгаенләнгән мәгънәсен искә төшерү сорала. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә:

**Сәнгать**- и. 1. Иҗтимагый аңның чынбарлыкны нәфис образлар аша чагылдыра торган формасы; дөньяны эстетик танып белү. 2. Иҗади эшчәнлекнең бер төре: чынбарлыкны нәфис образлар аша сурәтләп бирү иҗаты [30].

Димәк, сәнгатьчә әдәбият дигәндә, чынбарлыкны, ягъни адәм баласын чолгап алган табигатьне, тормыш-көнкүрештәге яшәешне, эчтәлеге һәм формасы ягыннан эстетик категорияләр халәтендә күзаллау, мөнәсәбәт белдерү һәм нәфис, гүзәл образ-сүз-сурәтләр белән сәнгатьчә иҗат ителгән әдәби әсәрне күздә тотабыз.

Иҗади эшчәнлекнең бер төре булуы истә тотылып, Л. Җәләй сәнгатьчә әдәбият стиле дигән төшенчәне аның шәкертләре сәнгатьле сөйләм / матур әдәбият стиле дип кулланалар [22: 45]; Матур әдәбият теле / сәнгатьле сөйләм / матур әдәбият стиле дип, бер үк төшенчәне тел, сөйләм, стиль сүзләре белән аңлаталар [31: 219]. Бу уңайдан укытучыбыз Л. Җәләйнең: «Әдәб – гарәп сүзе, тәртипле, тәрбияле; әдиб / әдип – нәфис әсәрләр язучы; әдәбият сүзе дә шул ук тамырдан килеп чыккан – матур калыпка салынган тел; матур әдәбият дигәндә, матур сүзе артык, матур-матур / красивая литература була. Наданлык нишләтми ул, мөгез булып чыкса, татар башы мөгездән генә торыр иде», – дигән фикере дә хәтердә. Әмма кулланышта матур әдәбият стиле дигән атама тотрыклылана.

Сәнгать сүзеннән аермалы буларак, стиль – күп мәгънә белдерә торган төшенчә [30: 672]. Татар филологиясендә аны беренче мәртәбә Казан университетының төрек-татар кафедрасы профессоры Н.Ф. Катанов «Материалы к изучению Казанско-татарского наречия» хезмәтендә куллана. «Образцы книжной и устной литературы Казанских татар» бүлегенең керешен болай дип башлый: «В Казани лишь в последнее время стал вырабатываться особый стиль: одни (А.К. Насыров, А.А. Фейзъханов) стали употреблять слова своего и др. языков с коренными казанско-татар. грамматич. формами, а другие (А.Г. Максутов) стали употреблять современный турецкий язык. Оба направления обращаются за словами к языкам араб. и персид., даже тогда, когда есть свои татар. слова» [19: 4]. Автор стиль терминының теориясен аңлатмый, ә М. Ломоносов хезмәтеннән алып куллана. Н.Ф. Катанов әйткән бу фикер, беренчедән, үз вакытында С. Кукляшев («Язма татар

теле өч төргә – гади (простой), эш (деловой), гыйльми (ученый) телгә бүленә» [21: 3] һәм К. Насыйри [23] хезмәтләрендә күзәтелә, әмма «тел» дип аталган күренеш «стиль» дигән яңа термин белән кабатлап әйтелә. Икенчедән, төрки-татар телендә язылган әдәбиятта җанлы сөйләмә тел берәмлекләре белән бергә гарәп һәм фарсы алынмалары да XII–XIII гасырларда язылган текстларда ук инде иркен кулланылган, әлеге нигездә язма телнең аристократ-абруйлы һәм халыкчан сөйләмә дип кулланылуы билгеләнгән була һәм бу юнәлештәге өйрәнүләр алга таба да дәвам иттерелә [25: 105–12].

Татар язма әдәби теленең X–XIII гасырлардан башланган тарихын өйрәнү барышында, сәнгатьчә әдәбият стиленең дә, әдәби телнең башка стильләре кебек үк, дәверләр буена эзлекле рәвештә дәвам итеп килгән төрки-татар язмачылык тарихының буеннан-буена «чынбарлыкны нәфис образлар аша сурәтләп бирү иҗаты» буларак барлыкка килеп, катлаулы үсеш процесында формалашуы күренә. Татар әдәби теле тарихын, аның стильләре тарихы дип, эзлекле рәвештә өйрәнгәндә, Л. Җәләй тарафыннан әдәби телнең беренче стиле дип билгеләнгән сәнгатьчә әдәбият стиленә кадәр сәнгатьчә иҗади эшчәнлекнең, Илаһият тәгълиматына нигезләнеп сәнгатьчә илаһи / рухани әдәбият стиле дип яшәеш алуы, шул нигездә, әмма адәм балаларының дөньяви яшәешен тасвирлауга игътибар ителеп, сәнгатьчә илаһи / рухани / инсани әдәбият стиле дип формалашып дәвам итүе; XIX йөзнең соңгы чирегенә таба гасырлар буена традиция булып килгән илаһи / рухани төшенчәләре урынына аерым персонажның исеме (Хисаметдин менла, 1886) алга куелып, конкрет тормыш шартларында тасвирлануы белән, сәнгатьчә инсани әдәбият стиле дип исемләргә мөмкин иҗади эшчәнлекнең безнең көннәргә кадәр төрле үзгәрешләр белән дәвам итүе мәгълүм була. Әдәби тел тарихын, аның стильләре тарихы дип өйрәнү барганда, һәр стильдә язылган әдәби әсәрнең, гасырлар буена эзлекле рәвештә илаһият тәгълиматына нигезләнгән сәнгатьчә язма традициядә, автор аңында эстетик кабул ителгән дөньяви чынбарлыкны үзенчә тасвирлаудагы яңарышы белән хәрәкәттә булуы, иҗтимагый тормыш шартларына бәйле рәвештә яңартыла баруы аңлашыла.

Мәкалә кысасында катлаулы мәсьәләләргә киңәеп тукталып булмый. Тарихи планда караганда гына күренә һәм аңлашыла торган катлаулы, үзенчәлекле проблемалар, «...татар халкының рухи мирасы булган, татар телен төрле яклап, тирәнтен... фәнни тикшерү» кирәклеген ассызыклаган [2] таләпкә туры китерелеп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтында, махсус проект буларак ачылып, «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы)...» дип өйрәнелә башлады. Хезмәтне, «Әдәби тел тарихын өйрәнү, гомумтел элементларын билгеләү һәм тикшерүгә, шулай ук тел системасының гомумграмматик һәм лексик-семантик категорияләрен аңлауга нигезләнә» дигән мәгълүм кабул ителгән теория истә тотылып [3: 278], гомумтелнең аерым тармакларына нигезләп тикшерү зарур.

1 нче томда фонетика / графика тармагына [25], 2 нче томда грамматика / морфология тармагына [26], 3 нче томда лексика / семантика тармагына [27; 28] мөнәсәбәтле проблемалар күз уңына куелды. Әдәби телнең һәр чоры, шул дәвердәге истәлекләрне тикшерүче белгеч буларак танылган, ягъни монографияләре басылып, фән кандидатлары, докторлары дәрәҗәсендә студентларга махсус курс алып баручы Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадирова, И.Б. Бәширова кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелеп, укучыларга тәкъдим ителде. Гомумтелнең элемент / тармакларына нигезләнеп, язма әдәби тел тарихының эзлеклелеген билгеләргә һәм тел системасының категорияләрен аңларга мөмкинлек биргән юнәлештәге тикшерүнең методологик нигезе, метод / ысул, принцип / алымнары, әлеге эшчәнлекнең татар филологиясендә ничек өйрәнелгәнлеге, алга таба анализның ничек барырга тиешлеге турындагы төп фикер проект җитәкчесе тарафыннан бөтен томнар өчен уртак гомуми керештә ассызыкланды. Һәр томда, татар язма әдәби теленең тарихы, аны яшәтүче конкрет тармакларның тарихы буларак күзалланып, аерым тема булып күтәрелде. Һәр авторның монография / хезмәтләрендә, үзе теләгәнчә төрле принципта анализланган мәсьәләләрнең нәтиҗәләрен, әдәби телнең тарихи эзлеклелеген билгеләү максатына туры китереп, мөнәсәбәт белдерергә кирәк булды; әдәби телнең тарихын өйрәнү – аның гомумтел элемент / тармаклары белән гомумграмматик һәм лексик-семантик категорияләренең тарихын күзаллап анализлау булуын истә тотып, метод / ысулы, принцип / алымнары һәр томның керешендә җентекләп аңлатылды [25: 206–232].

Хезмәтнең структур төзелешенә туры китереп, 3 нче томның 2 нче кисәге гомумтелнең синтаксис тармагына нигезләнеп тикшерүгә багышланды. Әлеге фәннең үзенә хас нәзари һәм гамәли мәсьәләләрен аңлау өчен, Л. Җәләйнең шәкерте, остазыбыз М.З. Зәкиевнең «Татар грамматикасы. Синтаксис» [17] хезмәтенә мөрәҗәгать итеп, төп фикерләрен зиһенгә алырга кирәк булды. Әлеге теорияне әдәби тел тарихын барлыкка китерә торган стильләр тарихы дип тикшерелә торган темабызга туры китерергә, ягъни аның стилистика фәне белән уртаклыгы булуга игътибар итәргә кирәк иде. Әлеге мәсьәләнең танылган тел галиме, методист-педагог, Л. Җәләйнең шәкерте С.М. Ибраһимовның «Синтаксик стилистикадан күнегүләр» (1968), «Синтаксик синонимнар һәм аларның төрләре» (1970), «Синтаксик стилистика» (1989) дигән хезмәтләрендә «сөйләм берәмлекләрен стилистик куллану үзенчәлегенә караган» фикерләрендә хәл ителүе билгеле [32: 160]. С.М. Ибраһимов, стиль дип сүз башлаганда, профессор В.Х. Хаковның: «Матур әдәбият әсәрләренең телен башка стильләр белән бер рәткә куеп булмый. Ул функциональ-сөйләм стильләренә караганда бик киң һәм үзендә телдәге барлык стильләрнең дә үзенчәлекләрен чагылдыра, шулай ук анда укучыга эстетик тәэсир итү көчле була, художестволы сурәтләү чараларына зур урын бирелә һәм язучының индивидуаль стиль үзенчәлекләре киң чагылыш

таба», – дигән фикерен инкяр итүдән башлый. Хаклы рәвештә болай ди: «...Һәр стильнең үз кануннары, үз таләпләре бар. ...синтаксик синонимнарны сайлап алуда, бу факторны тормышка ашыру өчен, функциональ стильләрнең теоретик нигезе дә җентекле эшләнгән булырга тиеш. Әлегәчә матур әдәбият стилен гомуми бер стиль дип, ул башка стильләрнең кушылмасын тәшкил итә, анда публицистика, хатлар, фәнни популяр һәм гади сөйләм стилен дә табарга мөмкин дип карау, әдәби әсәрнең теленә әйтеп бетергесез зыян китерә. Әдәби стиль – үзе бер мөстәкыйль стиль һәм ул үз юлы белән барып камилләшергә тиеш тә», дип, функциональ стильләр саналып китә: матур әдәбият стиле, публицистика стиле, фәнни стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хатлар стиле [18: 3–20]. Алга таба синтаксик категорияләрнең (синоним, омоним, тәңгәл, сүзтезмә һ. б.) аерым стиль таләбенә кирәкчә ярашып файдалану тиешлеге мәсьәләсе игътибар үзәгенә куела, аерым сөйләм стильләренең үзенә кирәк тел стильләре берәмлекләрен сайлап алуы белән башкалардан аерымлануы, бу юнәлештә синтаксис һәм стилистика дигән фән тармакларын берләштереп тикшерергә кирәк булуы ассызыклана.

Без, остазларыбызга догада булып, аларның фикерләренә нигезләнәбез. «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). 3 т. 2 кисәк. Синтаксис. Сөйләм стильләре һәм Тел стильләре. Илаһият тәгълиматына нигезләнгән сәнгатьчә язма традиция һәм дөньяви чынбарлыкны тасвирлаудагы яңарыш» дип тикшерелә торган монографиянең 3 нче томының 2 нче кисәген язу барышында, гомумтелнең сөйләм өйрәнелә торган синтаксис һәм текст синтаксисы тармагына караган мәсьәләләре истә тотылып, Л. Җәләйнең хезмәтләрендә стиль, стилистика дип күтәрелгән фикерләргә игътибар бирелде.

Әсәрнең темасы, башламы дип сүз башлау белән, XIII гасырдан алып, XIX гасырның ахырына кадәр татар сәнгатьчә әдәбият стиленең, бисмилләһир-рахмәнир-рахим дигән аять белән бергә (аятьне төрле кеше төрлечә яза, әлеге шәкелнең аять булуы һәм язылышы «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» хезмәтенә нигезләнеп бирелә) (20), Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дип, илаһият тәгълиматы традициясендә башлануы һәм авторның үз чоры дөньяви яшәешен тасвирлавы белән яңартылып дәвам иттерелүе мәгълүм була. Шуңа күрә тема «Илаһият тәгълиматы традициясендә дөньяви чынбарлыкны сәнгатьчә тасвирлаудагы яңарыш» дип ачыкланды. Үз вакытында Л. Җәләй тарафыннан күрсәтелә алмаган «Сәнгатьчә илаһи / рухани» һәм «Сәнгатьчә илаһи / рухани / инсани» әдәбият стиле дип исемләргә мөмкин ике стиль урыннарына куелды. Бу том басмага әзерләнде. Шулай итеп, остазыбыз, олуг галим, танылган педагог Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдиновның (Л. Җәләйнең) тууына 130 ел тулган көннәрдә дә киңкырлы эшчәнлегенең актуаль булуы, аның үзенең һәм шәкертләренең фикер юнәлешләрендә фәнни тикшеренүләрне дәвам итү мөмкинлеге күренде. «Татар әдәби теле тарихы. XIII гасыр – XX йөз башы...» дип башланган теманы гомумтелнең һәр дүрт

тармагына нигезләп тикшерү белән аерым проект булып ачылган фәнни тикшеренүнең тәмам булуын куанып әйтә алабыз.

Татар халкының үз карамагында мәктәп-мәгарифе булмаган XX йөз ахыры – XXI йөз урталарындагы вазгыятьтә татар халкының сөйләмә һәм язма әдәби теленең (стильләренең) иҗтимагый тормыш шартлары таләбенә җавап бирү юнәлешендәге катлаулы үсеш-үзгәрелеш мәсьәләләрен һәм теоретик, һәм гамәли нигездә өйрәнүнең актуаль тема булып күтәрелүе мәгълүм [1, 24 һ. б.]. Димәк, яңа проблемаларны өйрәнү өчен, яңа проект ачу өчен ныклы нигез салынганлыкка ышаныч белдереп, алга таба бу мөһим юнәлештә эшчәнлек дәвам итәр, дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**


1. *Абдуллина Ч.З., Сагдеева Ф.К.* Языковая ситуация в Республике Татар стан: сферы применения татарского языка. Казань: Школа, 2021. 136 с.

2. *Бәширова И.Б.* Татар стилистикасының теоретик нигезләре: Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа. Казан, 2005. Б. 21–25.

3. *Виноградов В.В.* История русских лингвистических учений. М.: Высшая школа, 1978. 367 с.

4. *Дмитриев Н.К.* Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 4. Казань, 2005. С.5.

5. *Җәләй Л.* Әдәби мөсабәкәләр. Татар шагыйрьләре «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. Оренбург, 1913. 23 март.

6. *Җәләй Л.* Стилистика һәм әсәрнең композициясе. Тәрҗемәчеләр белән уку өчен бер курс. 1934. 36 б.; Стилистика һәм гомуми тел белеме буенча язмалар. 1935. 38 б. // Язма мирас үзәге. Ф. 29, тасв. 1, сакл. бер. 4.

7. *Җәләй Л.* Практик стилистика алдында торган төп бурычлар // Мәгариф. 1935. №11. Б. 3–8.

8. *Җәләй Л.* Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең аерымланган кисәкләре // Совет әдәбияты.1935. № 12. Б. 87–95.

9. *Җәләй Л.* Әдәби телне өйрәник! (Ә. Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр» повестена карата) // Совет әдәбияты. 1953. №7. Б. 121–124.

10. *Җәләй Л.* Татар теле әдәби теле туу мәсьәләсенә карата // Совет әдәбияты. 1956. № 12. Б. 91–99.

11. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: Фикер, 2000. Б. 12, 16, 17, 18, 20, 34, 35 һ. б.

12. *Җәләй Л.* Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты. 1938. № 3, 4, 5.

13. *Җәләй Л.* Рец.: «Сиваш» (Г. Разин әсәре, 1937 ел) // Совет әдәбияты. 1938. № 6. Б. 84–103.

14. *Җәләй Л.* Рец.: «Үч» (Г. Бәшировнең хикәяләр җыентыгы, 1943) // Кызыл Татарстан. 1943. 9 июнь.

15. *Җәләй Л.* «Намус турында»// Язма мирас үзәге. Ф. 75, тасв. 2, сакл. бер. 3.

16. *Зәйнуллин Җ.Г.* XVIII – XX йөз башында татар рухани әдәбияты: Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ. б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре. Казан: Мәгариф, 1998. 207 б.

17. *Зәкиев М.З.* Татар грамматикасы: өч томда, 3 т.: Синтаксис. Казан, 1999, Б. 5–14; 450–483.

18. *Ибраһимов С.М.* Синтаксик стилистика. Студентлар өчен кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. 150 б.

19. *Катанов Н.Ф.* Материалы к изучению Казанско-татарского наречия. Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1898. Ч. 1: Образцы книжной и устной литературы казанских татар. 1898. 168 с.

20. Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә. Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2020. 808 б.

21. *Кукляшев С.* Татарская хрестоматия. Казань: Университетская тип., 1859. 124 с.

22. *Курбатов Х.Р.* Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М.: Наука, 1978. 217 с.

23. *Насыйри К.* Ысулы җәгърафия кәбир. Казан, 1898 // Сайланма әсәрләр. ике томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 84–87.

24. *Сагдеева Ф.К.* Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка). Казань, 2025. 206 с.

25. Татар әдәби теле тарихы / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадирова; ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2015. 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма и вариантлылык. 696 б.

26. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.Ф. Мирхәев; ф. ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2017. II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 888 б.

27. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, М.З. Вәлиева, Г.Ф. Гайнуллина, Х.Х. Кузьмина; ф. ред. Ф.С. Баязитова. Казан: ТӘһСИ, 2019. III т.: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариант-парадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Беренче кисәк. 528 б.

28. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, М.З. Вәлиева, Р.Ф. Мирхәев; ф. ред. Ф.С. Баязитова. Казан: ТӘһСИ, 2020. III т.: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариант-парадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Икенче кис. 588 б.

29. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 8.

30. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 2 т. Казан, 1979. Б. 710.

31. *Хаков В.Х.* Хәзерге татар әдәби теле. (Стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

32. *Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* Татарстан галимнәренең фәнни-методик мирасы: Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимов (галим-методистның тууына 95 ел) // Фәнни Татарстан. 2023. № 4. Б. 160.

33. Языки мира. Тюркские языки. Бишкек, 1997. С. 160, 395, 413,427, 438, 358.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе*

***Баширова Илида Басыровна,***
*доктор филологических наук,*
*заслуженный деятель науки Республики Татарстан*
*lilvil25@mail.ru*